РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

29.01.2020 | № 116-п

Саба муниципаль районы мәгариф учреждениеләрендә эшләүче педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә акча түләү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә акча билгеләү турында”гы 2018 елның 29 декабрендә кабул ителгән 1270 номерлы карары нигезендә һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә дәүләт ярдәме күрсәтү һәм педагогик кадрларны беркетү максатыннан, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты:

КАРАР БИРӘ:

1. Саба муниципаль районы мәгариф учреждениеләрендә эшләүче педагогик хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә акча түләү тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә - Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе” МКУ башлыгы И.Ф. Шакировка йөкләргә.

Җитәкче М.Р.Ишниязов

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Башкарма комитетының

________________________

________________________

номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

**Саба муниципаль районы мәгариф учреждениеләрендә эшләүче педагогик хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә акча түләү тәртибе**

1. Әлеге тәртип Саба муниципаль районының муниципаль мәгариф учреждениеләрендә (алга таба – оешма) эшләүче педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә акчаның күләмен һәм түләү тәртибен билгели.

2. Педагогик хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә акчаны түләү, әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга, тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган акчалар хисабына башкарыла.

3. Әлеге тәртиптә педагогик хезмәткәр – яшь белгеч дип 30 яшькә кадәрге, беренче тапкыр көндезге формада һөнәри белем бирү оешмасын яки югары белем бирү программалары - бакалавриат, специалитет, магистратура, аспирантура программалары буенча дәүләт аккредитациясе булган югары белем бирү мәгариф оешмасын тәмамлаган (алга таба - һөнәри белем бирү оешмасы, югары белем бирү мәгариф оешмасы), һәм һөнәри белем бирү оешмасын яки югары белем бирү мәгариф оешмасын тәмамлаган елның 1 ноябреннән дә соңга калмыйча, һөнәри белем дәрәҗәсе һәм квалификациясе нигезендә, хезмәт килешүе буенча оешмага эшкә алынган зат таныла.

4. Педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә акча билгеләү хокукы түбәндәге оешмаларда бирелә:

мәктәпкәчә белем бирү оешмалары;

гомуми белем бирү оешмалары;

өстәмә белем бирү оешмалары.

5. Педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә акча эшкә урнашу датасыннан педагогик вазыйфада өзлексез эшләүнең беренче өч елы дәверендә билгеләнә.

Педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә акча түләүне билгеләү, туктату, озайту турындагы карар Оешма боерыгы белән раслана.

6. Әлеге Тәртипнең 3 пунктында билгеләнгән айлык стимуллаштыручы өстәмә акча алу өчен эшкә урнашу вакытын үткәрүнең мөһим сәбәпләренә түбәндәгеләр керә:

– документаль рәвештә расланган вакытлыча эшкә сәләтсез дип танылу;

– Россия Федерациясе Кораллы көчләрендә чакырылыш буенча хәрби хезмәт үтү яки альтернатив гражданлык хезмәте үтү;

– йөклелек һәм бала табуга бәйле ял,кечкенә баланы аңа өч яше тулганчы карау һәм тәрбияләү ялы.

Педагогика хезмәткәр - яшь белгеч, вакытлыча эшкә сәләтсез дип танылган вакыты, Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә чакырылыш буенча хәрби хезмәт үтү яки альтернатив гражданлык хезмәте үтү вакыты, йөклелек һәм бала табуга бәйле ял вакыты, кечкенә баланы аңа өч яше тулганчы карау һәм тәрбияләү ял вакыты тәмамланган көннән алып 60 көннән дә соңга калмыйча хезмәт мөнәсәбәтләрен рәсмиләштергән очракта, айлык стимуллаштыручы өстәмә акча билгеләнергә мөмкин.

7. Хезмәткәрнең хәрби хезмәткә чакырылуына яки хезмәткәрнең аны алыштыручы альтернатив граждан хезмәтенә җибәрелүенә бәйле рәвештә хезмәт килешүе туктатылган очракта һәм педагогик хезмәткәр-яшь белгеч Россия Федерациясе Кораллы көчләрендә чакырылыш буенча хәрби хезмәт яки альтернатив граждан хезмәте үткәннән соң хезмәт мөнәсәбәтләрен 60 көннән дә соңга калмыйча рәсмиләштергән очракта, айлык стимуллаштыручы өстәмә акча өч ел эшләү дәверендә кабат билгеләнергә мөмкин.

8. Оешма белән хезмәт мөнәсәбәтләрендә торучы педагогик хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә акча түләү түбәндәге чорларда туктатыла:

йөклелек һәм бала табуга бәйле ял, кечкенә баланы аңа өч яше тулганчы карау һәм тәрбияләү ялы;

аспирантурада көндезге бүлектә белем алу.

9. Башка оешмадагы педагогик вазыйфага күчкәндә 30 көннән дә артык булмаган ял вакыты рөхсәт ителә.

10. Оешмадагы кеше санының яисә штатның кыскаруына бәйле рәвештә педагогик хезмәткәрне - яшь белгечне эштән чыгарган очракта, киләчәктә педагогик вазыйфага эшкә урнашканчы 60 көннән дә артык булмаган ял вакыты рөхсәт ителә.

11. Педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә акча, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның педагогик хезмәткәрләре вазыйфалары,”Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның педагогик хезмәткәрләре вазыйфалары, белем бирү оешмалары җитәкчеләре вазыйфалары номенклатурасын раслау турында”гы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 8 августындагы 678 номерлы карары белән расланган белем бирү оешмалары җитәкчеләре вазыйфалары номенклатурасының 1 бүлегендәге 2 пункты нигезендә педагогик хезмәткәрләрнең вазыйфалары буенча билгеләнә.

12. Педагогик хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә акча педагогик хезмәткәр-яшь белгечнең төп эш урыны буенча гына билгеләнә.

13. Педагогик хезмәткәрләргә-яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә акча төп педагогик вазыйфа буенча һәм эше әлеге педагогик хезмәткәр - яшь белгеч тарафыннан эчке берләшү шартларында башкарыла торган педагогик вазыйфа буенча билгеләнә.

14. Хезмәт хакы ставкасы өчен атнага (елга) педагогик эш сәгате нормалары билгеләнгән педагогик хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә акча күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$D = P \times H_f / H_n$$

Монда:

D – Хезмәт хакы ставкасы өчен атнага (елга) педагогик эш сәгате нормалары билгеләнгән педагогик хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә акча күләме, әмма аена 1111 сумнан да артык түгел;

P – педагогик хезмәткәрләргә-яшь белгечләргә атнага (елга) педагогик эш сәгате нормасы өчен 1111 сум күләмендә стимуллаштыручы өстәмә акча;

Hf - педагогик эш алып бару сәгатьләренең факттагы саны;

Нн – хезмәт хакының база күләме өчен сәгать нормасы.

15. Педагогик хезмәткәрләргә-яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә акча күләме (айлык стимуллаштыручы өстәмә акчасы әлеге Тәртипнең 12 пункты белән билгеләнгән педагогик хезмәткәрләрдән - яшь белгечләрдән тыш) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$D = P \times t$$

Монда:

D - педагогик хезмәткәрләргә-яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә акча күләме, әмма аена 1111 сумнан да артык түгел;

P - педагогик хезмәткәрләргә-яшь белгечләргә хезмәт хакы ставкасы өчен 1111 сум күләмендә стимуллаштыручы өстәмә акча;

т-факттагы эшләнгән вакыт.

16. Педагогик хезмәткәрләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә акча Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган субсидияләр хисабына түләнә.